КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 20 декабрь г.Казань № 1177

2025 елда Татарстан Республикасында «Радиоэлектроника аппаратурасы монтажнигы» номинациясендә «Һөнәре буенча иң яхшы» бөтенроссия һөнәри осталык конкурсының федераль этабын оештыру турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Халыкны эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 15 апрелендәге 298 номерлы карары нигезендә һәм «Һөнәре буенча иң яхшы» бөтенроссия һөнәри осталык конкурсының федераль этабын уздыруга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2025 елның 22 сентябреннән 26 сентябренә кадәр Татарстан Республикасында «Радиоэлектроника аппаратурасы монтажнигы» номинациясендә «Һөнәре буенча иң яхшы» бөтенроссия һөнәри осталык конкурсының (алга таба – Конкурс) федераль этабын уздырырга.

2. Бу карарга теркәлгән 2025 елда Татарстан Республикасында «Радиоэлектроника аппаратурасы монтажнигы» номинациясендә «Һөнәре буенча иң яхшы» бөтенроссия һөнәри осталык конкурсының федераль этабын әзерләү һәм уздыру буенча республика оештыру комитеты (алга таба – оештыру комитеты) составын расларга.

3. Оештыру комитетына 2025 елның 15 гыйнварына кадәр Конкурсның федераль этабында катнашучыларның һөнәри осталыгын бәяләү өчен Конкурс уздыру буенча эксперт комиссиясе составын расларга.

4. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгын түбәндәгеләр итеп билгеләргә:

2025 елда «Хезмәт кешесе» федераль проекты кысаларында «Радиоэлектроника аппаратурасы монтажнигы» номинациясендә «Һөнәре буенча иң яхшы» бөтенроссия һөнәри осталык конкурсының федераль этабын оештыруга юнәлдерелгән чараларны

гамәлгә ашыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субсидия бирү өлешендә Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең баш администраторы;

Россия Федерациясенең Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы белән хезмәттәшлек итү һәм Конкурсны уздыру эшен координацияләү буенча вәкаләтле орган.

5. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

Конкурс уздыруны финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан «Радиоэлектроника аппаратурасы монтажнигы» номинациясендә «Һөнәре буенча иң яхшы» бөтенроссия һөнәри осталык конкурсының федераль этабын оештыруга юнәлдерелгән чараларны финанс белән тәэмин итү буенча Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында 2025 елда федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган субсидия акчасы һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы (алга таба – бюджет акчасы) исәбеннән гамәлгә ашырыла;

2025 елда «Радиоэлектроника аппаратурасы монтажнигы» номинациясендә «Һөнәре буенча иң яхшы» бөтенроссия һөнәри осталык конкурсының федераль этабын оештыру чараларын гамәлгә ашыруга каралган бюджет акчасы белән баш эш итүче – Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы;

6. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына:

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы белән берлектә, Конкурста каралган практик биремнәрне уздыру өчен эш мәйданчыгын тәэмин итәргә;

Конкурсының башлануына яки тәмамлануына багышланган Конкурсны ачу һәм анда җиңүчеләрне бүләкләү тантанасын оештырырга (фестиваль һәм күргәзмә форматында яисә интерактив багланышларны һәм халык карауны күздә тоткан башка форматта гавами ачык чара үткәрүне кертеп);

Конкурсны уздыру буенча оештыру комитеты эшчәнлеген оештыру һәм техник яктан тәэмин итүне гамәлгә ашырырга.

7. «Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына Конкурсның федераль этабын мәгълүмат бирү характерындагы реклама белән тәэмин итүне оештырырга.

8. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына йөкләргә.

9. Бу карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Тәрҗемәче: А.М.Сәгыйтова

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 20 декабрь, 1177 нче
карары белән расланды

2025 елда Татарстан Республикасында «Радиоэлектроника аппаратурасы монтажнигы» номинациясендә «Һөнәре буенча иң яхшы» бөтенроссия һөнәри осталык конкурсының федераль этабын әзерләү һәм уздыру буенча республика оештыру комитеты составы

| | |
|---|---|
| Фазлыева Ләйлә Ринат кызы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, оештыру комитеты рәисе |
| Коробченко Олег Владимирович | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры, оештыру комитеты рәисе урынбасары |
| Поминов Андрей Иванович | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрының беренче урынбасары, оештыру комитеты рәисе урынбасары |
| Тажетдинова Клара Алексеевна | Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры урынбасары, оештыру комитеты секретаре |

Оештыру комитеты әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Белов Андрей Сергеевич | «В.И.Шимко исемендәге «Радиоэлектроника» фәнни-җитештерү берләшмәсе» акционерлык җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Выборнов Андрей Андреевич | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының югары, урта һөнәри белем бирү һәм фән бүлеге башлыгы |
| Гобәйдуллин Эмиль Фидаил улы | «Һөнәри компетенцияләрне үстерү үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасы генераль директоры (килешү буенча) |
| Карпов Родион Михайлович | Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрының беренче урынбасары |
| Кузьмичева Елена Ивановна | Татарстан Республикасының Һөнәр берлекләре федерациясе рәисе (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Мөхәммәтов Камил Баязит улы | «Казан радиомеханика көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе директоры |
| Начвин Илья Сергеевич | Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрының беренче урынбасары |
| Рассман Игорь Олегович | Татарстан Республикасының Предприятиеләр һәм сәнәгатьчеләр ассоциациясе (эш бирүчеләрнең төбәк берләшмәсе) генераль директоры урынбасары |
| Сабирова Айгөл Азат кызы | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министры урынбасары |
| Сабурская Алина Викторовна | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Социаль үсеш идарәсе башлыгы. |

_______________________________